ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 74 от «19» 02 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитеты каршындагы
Әтиләр Советы Нигезләмәсенә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Гаилә һәм балачак институтларын ныгыту һәм үстерү мәсьәләләрендә ир-атларның эшчәнлеген активлаштыру максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты  к а р а р  б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 мартындагы 242 карарына 2 нче Кушымта булып расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Әтиләр Советы Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр:

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Совет рәисе Совет белән гомуми җитәкчелек итә, Советның эш юнәлешләрен һәм планын билгели, раслый, комиссия утырышлары беркетмәләренә, беркетмәләрдән өземтәләргә кул куя, Совет кабул иткән карарларны раслый, Совет кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тота.

Совет секретаре Совет эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, Советның документ эшен  алып бара, Совет әгъзаларын һәм аның утырышына чакырылган затларга көн тәртибе, үткәрү датасы, урыны турында хәбәр итә, фикер алышуга кагылышлы документларның проектларын һәм башка материалларны җибәрә, Совет утырышларын әзерләүне оештыра.

1. 4.6. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Совет карары совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Совет утырышында кабул ителә торган карарлар утырышта рәислек итүче һәм секретарь кул куйган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Совет утырышлары беркетмәләренең күчермәләре Совет утырышы уздырылганнан соң 3 эш көне эчендә аның әгъзаларына җибәрелә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

0000010782

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов